БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 июль 2025 ел № 330

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләренең генераль планын әзерләү кирәк түгеллеге турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының кайбер авыл җирлекләре территориясендә әлеге җирлек территорияләреннән гамәлдәге файдалануны үзгәртү күздә тотылмау һәм социаль-икътисадый үсешнең расланган стратегияләре булмау, шулай ук җирлекләр территорияләрендә Россия Федерациясе территориаль планлаштыру документлары, Россия Федерациясе субъектын территориаль планлаштыру документлары, Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру документлары белән федераль әһәмияттәге объектларны,региональ әһәмияттәге объектларны, муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектларны әлеге җирлекләр территориясендә урнаштыру каралмау сәбәпле һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының түбәндәге авыл җирлекләренең генераль планын 2025 елның «31» декабренә кадәр эшләү кирәк түгеллеген танырга:

- Карадуган авыл җирлеге;
- Шеңшеңәр авыл җирлеге;
- Югары Субаш авыл җирлеге;
- Нөнәгәр авыл җирлеге.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Татарстан Республикасының 2023 елның 23 декабрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 131-ТРЗ номерлы Законы нигезендә 1 пунктта күрсәтелгән авыл җирлекләрендә җирдән файдалану кагыйдәләре һәм төзелеш проектын әзерләү турында карар кабул итү тәкъдиме белән Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (http://baltasi.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач Район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин